**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Кәкре Атау авылы торак пункты гражданнар җыены КАРАРЫ**

«29» октябрь 2024 ел № 14

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлеге Кәкре Атау торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлегенең Кәкре Атау торак пункты территориясендә һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган салымны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җЗ,ирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

урамнарны яктырту җайланмасы.

су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, торак пункт территориясен төзү һәм ремонтлау.

Халык җыенында рәислек итүче: Н.В.Авдеева

Гәйтән авыл җирлеге башлыгы Н.В.Авдеева